Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Югары Шытсу торак пунктында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

15.11.2019 № 1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Югары Шытсу торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 23 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең Югары Шытсу торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Түбән Шытсу авыл җирлеге Югары Шытсу торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Югары Шытсу авылының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shitsi бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов